СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2016 елның «28» июненнән** **№ 15-61**

**«Пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затларны муниципаль милек өчен аренда түләвеннән азат итү турында»**

Яжа Чишмә муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы:

**КАРАР БИРӘ:**

1.2016 елның 1 гыйнварыннан пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затларны муниципаль милектән (пассажирлар йөртү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен турыдан-туры кулланыла торган) файдаланган өчен аренда түләвеннән азат итәргә. Әлеге карар алданрак барлыкка килгән һәм 2016 елда гамәлдә булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**